ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 декабрь, 2017 ел № 21/12

Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

2015 елның 13 июлендәге «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны регуляр йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 220-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2017 елның 20 июлендәге "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 59-ЗРТ санлы Законы, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә автомобиль һәм гомуми файдаланудагы шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә (Шәһәр Советының 2017 елның 20 июнендәге 17/9 санлы Карары редакциясендә)

түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 7 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 11 пунктча өстәргә:

«11) кирәк булган очракта, муниципаль маршрутларда җайга салынмый торган тарифлар нигезендә даими рәвештә пассажирлар йөртүгә таләпләр билгеләү;»;

2) 46 пунктның 4 пунктчасында «кеше сәламәтлегенә авыр зыян китергән» сүзләреннән соң «яки кеше үлеменә китергән» сүзләрен өстәргә;

3) 46 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктча өстәргә:

«5) Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән очракта - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив-хокукый акты белән билгеләнгән җайга салынмый торган тарифлар нигезендә пассажирлар йөртү таләпләрен бер ел эчендә кабат бозган өчен.».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев